**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Карамалинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы, Азнакаевского муниципального района, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты**

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«14» декабря 2017 г. № 24

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Карамалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар һәм биналар исемлеге һәм биналар бирү тәртибе турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына гавами чаралар турындагы законнарны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 7 июнендәге 107-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар исемлеге (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен биналар исемлеге (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү тәртибе (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Ногманов А.Р.